ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унөченче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унөченче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне билгеләп кую турында.
4. Захарова Светлана Михайловнаның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.
6. Баксиков Рәсим Рәшит улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты составындагы үзгәреш турында.
8. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 114-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 105-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «2026 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 108-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә

ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 103-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 102-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 104-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 101-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 110-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 107-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 106-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 112-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 111-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 96-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 109-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 113-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 97-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

24. «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 99-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

25. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составындагы үзгәреш турында.

26. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисен сайлау турында.

27. Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.

28. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 954008-8 номерлы федераль закон проекты хакында (торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен бурыч күләмен киметү өлешендә).

29. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 375-VII ДС